**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ**

**Нижнеалькеевского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы**

**Түбән Әлки авыл Жирлеге**

**СОВЕТЫ**

Адрес: 422884, РТ, с. Нижнее Алькеево, ул. Советская, д 55

тел.: : 8 (84346) 77-2-15

Адресы: 422884, РТ, Түбән Әлки авылы, Совет ур. 55

тел: 8 (84346) 77-2-15

РЕШЕНИЕ Түбән Әлки КАРАР

2025 елның " 08 " августы № 89

Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге Советының 23.10.2023 елның 42 нче номерылы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы "Түбән Әлки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында " карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлки районы Прокуратурасының хокук булдыру инициативасын өйрәнеп, муниципаль берәмлек Уставының 85,86 статьялары нигезендә «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Түбән Әлки авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Әлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 23.10.2023 елның 42-нче карары белән (29.07.2024 елның 62-нче карары редакциясендә) 1 нче кушымта нигезендә расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Әлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Әлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Әлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Түбән Әлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы статьяларының яңа редакциясен дәүләт теркәвенә алганнан соң Түбән Әлки авыл җирлеге территориясендә: Татарстан Республикасы, Әлки районы, Түбән Әлки авылы, Совет урамы, 55нче йорт (җирле үзидарә бинасы), Түбән Әлки авылы, Мәктәп ур., 28нче йорт (авыл мәдәният йорты) һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында (http://alkeevskiy.tatarstan.ru.) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
«Түбән Әлки авыл җирлеге»
Советы Рәисе,
Муниципаль берәмлек башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Ф.Ф.Мисалов

1 нче кушымта
Әлки муниципаль районы
Түбән Әлки авыл җирлеге
Советы карарына
08.08.2025 ел, № 89

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Түбән Әлки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 19.1 пункт өстәргә:

"19.1" шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112 номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып барган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру".